# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(IV чакырылыш)

## КАРАР

IV чакырылыш бишенче утырышы

07 апрель 2021 ел № 42 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районының административ комиссиясен төзү
турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 30.12.2005 елдагы 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының административ комиссиясен төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетына:

- административ комиссия төзергә;
- административ комиссия составын расларга;
- административ комиссиянең эш регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм

порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Башлыгы -

Татарстан Республикасы Ютазы район

Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин